ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.01.2021 — 2

с. Коргуза

2021нче елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Мәет җирләү һәм күмү эше турында» 1996нчы елның 12нче гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 нчы статьясындагы 3нче пункты һәм 12нче статьясындагы 3нче пункты, «2021нче елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021нче елның 28нче гыйнварындагы 73нче номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны һәм «Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010нчы елның 15нче июнендәге 468нче номерлы Федераль законы, Карагуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021нче елның 1нче февраленнән башлап, 1нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6424,98 сум күләмендә хезмәт күрсәтү бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы — С. А. Сакин

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2021нче елның
29нчы гыйнварыннан
2нче номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегендә 2021нче елның 1нче февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3322,18 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 1030,12 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2072,68 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021нче елның 29нчы гыйнварыннан 2нче номерлы карарына

2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегендә 2021нче елның 1нче февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | —- |
| 2. Мәетне кәфенләү | 614,71 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 2707,47 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 1030,12 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2072,68 |
| Барлыгы | 6424,98 |